**Р Е С П У Б Л И К А**
**Т А Т А Р С Т А Н**
**Г Л А В А**
**Балтачевского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

**Т А Т А Р С Т А Н**
**Р Е С П У Б Л И К А С Ы**
***Кама Тамагы***
**м у н и ц и п а л ь р а й о н ы**
**Балтач авыл җирлеге**
**Б А Ш Л Ы Г Ы**

ул. Школьная, 1, с. Балтачево,
Камско-Устьинский район, 422829
тел./факс: (84377) 3-66-40
ОГРН 1061672018044
ИНН/КПП 1622004637/162201001

Мэктэп урамы, 1, Балтач авылы,
Кама Тамагы районы, 422820,
тел./факс: (84377) 3-66-40
ОГРН 1061672018044
ИНН/КПП 1622004637/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 9 ноябре** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халыкҗыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында гражданнар җыенын кертү һәм үзара салым акчаларын файдалану мәсьәләсе буенча билгеләү турында» 2020 елның 15 октябрендәге 5 номерлы карары үз көчен югалткан дип санау хакында»

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2020 елның 21 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка халык җыенын билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән , I төркем инвалидларыннан тыш , 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү, һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Балтач авылында авыл эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау ,таш сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Балтач авылы коесын ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Балтач авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, санитар-саклау зоналарын коймалау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль район, Балтач ав., Мәктәп ур., 1,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мәктәп урамы, 2 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәТатарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң 2 (ике) көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Балтач
авыл җирлеге башлыгы Д.И. Мөхәмәдуллин